| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.08.2023 Казан № 338-П

Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районында урнашкан «Мәлләтамак авылы XIII» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, чикләрен һәм махсус файдалану режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә б о е р а м:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районында урнашкан «Мәлләтамак авылы XIII» ачыкланган археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Расларга:

бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районында урнашкан «Мәлләтамак авылы XIII» ачыкланган археологик мирас объекты территориясенең чикләрен (бастырып чыгарылырга тиеш түгел);

бу боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районында урнашкан «Мәлләтамак авылы XIII» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән махсус файдалану режимын.

3. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә күрсәтелгән ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында мәгълүматларны Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Комитет рәисе И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 4 августындагы 338-П боерыгына 3 кушымта

Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районында урнашкан «Мәлләтамак авылы XIII» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән
**махсус файдалану режимы**

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану, шулай ук күрсәтелгән объектка гражданнарның керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләреннән файдалану мөмкинлеген күздә тота.